РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апреля 2024 ел г. Альметьевск № 1620

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урынны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак урынга күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 2023 елның 27 сентябрендәге 3550 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урынны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак урынга күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 2023 елның 27 сентябрендәге 3550 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 3.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.6.3, 3.6.4 пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.6.3. Торак яисә торак булмаган бина сыйфатында бинаны файдалануны тәэмин итү өчен аны яңадан урнаштыру, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр таләп ителмәгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 5 өлешендә каралган документ торак урынны торак булмаган бинага яисә торак булмаган бинаны торак урынга күчерү турында карар кабул итүне раслый торган документ күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора. Бу очракта күрсәтелгән күчерү мондый бинаны билгеләү турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән соң тәмамланган дип санала.

3.6.4. Яңадан үзгәртеп кору, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр буенча әлеге регламентының 3.6.3 пунктчасында күрсәтелгән эшләр тәмамлангач, күрсәтелгән үзгәртеп коруны, һәм (яисә) яңадан планлаштыруны һәм (яисә) башка эшләрне төгәлләү турында мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә төзелгән үзара хезмәттәшлек турында Килешү нигезендә, биналарны күчерелә торган бина урнашкан урын буенча турыдан-туры яки күп функцияле үзәк аша күчерүне

гамәлгә ашыручы орган аша хәбәрнамә җибәрә.

Бинаны яңадан планлаштырган очракта, мондый хәбәрнамәгә яңадан планлаштырылган бинаның техник планы беркетелә. Әлеге регламентның 3.6.3 бүлегендә күрсәтелгән үзгәртеп кору, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләрне тәгәлләү биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан төзелгән кабул итү комиссиясе акты белән раслана, (алга таба - кабул итү комиссиясе акты). Кабул итү комиссиясе актын раслау хәбәрнамәнең әлеге өлешендә күрсәтелгән биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы орган алган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Торак бинаны торак булмаган бинага яисә торак булмаган бинаны торак урынга күчерү, аны гамәлгә ашыру өчен бинаны күчерү турында карар кабул итүне раслый торган документ нигезендә яңадан корылу һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителгән торак бинага күчерү, бинаны билгеләү турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына үзгәрешләр кертелгән көннән алып тәмамланган дип санала. Торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, аны гамәлгә ашыру өчен бинаны күчерү турында Карар кабул итүне раслаучы документ нигезендә яңадан планлаштыруны үткәрү таләп ителгән, кучемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына мондый бинаның чикләре һәм (яки) мәйданы һәм билгеләнеше турында үзгәрешләр кертелгәннән соң яисә барлыкка килгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә һәм дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыру көненнән тәмамланган дип санала.»

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А. Р. Исхаковка йөкләргә (килешү буенча).

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов